| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.10.2024 Казан ш № 683

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән расланган Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 31.10.2016 №612, 08.06.2017 №349, 01.06.2018 №426, 18.09.2018 №860, 23.04.2019 №297, 14.11.2019 №1021, 10.02.2020 №84, 08.06.2020 №400, 04.09.2020 №609, 21.05.2021 №331, 01.10.2021 №711, 18.04.2023 №294, 10.01.2024 №3, 27.06.2024 №456 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның 4 октябрендәге 683 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән расланган Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документлар (белешмәләр) кермәгән очракта, бу Регламентның 3.4.2 пунктының беренче абзацында каралган срокта 10 эш көненә озайтыла.»;

2.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2. Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты тапшырылмаган очракта, шулай ук субсидия бирү турындагы гаризада һәм (яисә) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүмат булу факты ачыкланган очракта, гаризаны карау 10 эш көненә туктатып торыла. Гаризаны карауны туктатып тору турында хәбәр, исемлек нигезендә тапшырылырга тиешле документларның (белешмәләрнең) исемлеген һәм (яисә) төзәтелергә тиешле мәгълүматны күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә мондый карар кабул ителгән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче вәкаләтле органга субсидия бирү турында эшләп бетерелгән гаризаны һәм (яисә) әлеге гаризаны карауны туктатып тору турында хәбәрдә күрсәтелгән, эшләп бетерелгән документларны (белешмәләрне) тапшыра.

Субсидия бирү турында яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы мөрәҗәгать итүче документларның (белешмәләрнең) тулы комплектын тапшырган һәм (яисә) субсидия бирү турында эшләп бетерелгән гариза һәм (яисә) эшләп бетерелгән документлар (белешмәләр) вәкаләтле органга кергән көннән башлап яңартыла.»

2.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә артмаган срокта, дәлилләнгән нигезләмәне кәгазьдә күрсәтеп яисә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган

электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталдан яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, хәбәр җибәрелә, әгәр субсидия бирү турында гариза Бердәм портал яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелгән булса.» (Әлеге үзгәрешләрнең өченче-тугызынчы абзацлары таләпләре 2024 елның 25 декабреннән үз көченә керә)

2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

барлык гаилә әгъзаларын һәм туганлык дәрәҗәсен, почта адресын яисә кредит оешмасына социаль түләүләрне алу өчен федераль законнар нигезендә ачылган счетның реквизитларын күрсәтеп, (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә – әлеге пункт таләпләре нигезендә имзаланган) гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазь чыганактагы документ рәвешендә; электрон рәвештә (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда интерактив форманы тутыру юлы белән, нинди дә булса башка формада гариза бирү зарурлыгыннан тыш);

Мөрәҗәгать итүче шәхсән (килеп туган тормыш хәленә карап) бирә торган документлар:

мөрәҗәгать итүченең чит ил гражданинына һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе белән субсидия бирүне күздә тотучы халыкара килешү төзелгән дәүләт гражданлыгына караганлыгын таныклый торган документларның күчермәләре (күчермәсе нотариаль рәвештә таныкланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп);

мөрәҗәгать итүчегә торак урын һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен исәпләнгән суммалар турында һәм мөрәҗәгать итүченең торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгән суммалары турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән торак урынына ия булуының һәм аннан файдалануының хокукый нигезләрен раслый торган белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (тиешле акт язуы чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта);

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (тиешле акт язуы чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта);

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (тиешле актны чит дәүләтнең компетентлы органы теркәгән очракта);

Россия Федерациясе Торак кодексының 31 һәм 69 статьялары нигезендә мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзалары булган туганнары һәм хезмәткә сәләтсез тәрбияләнүчеләр турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче белән даими яшәү урыны буенча бергә яшәүче затларны суд тәртибендә аның гаилә әгъзалары дип тану турында белешмәләр;

хезмәт яисә башка бурычларны, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, граждан-

хокукый шартнамә кысаларында, шул исәптән түләүле шартларда опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) (шул исәптән салым тотып калынган) буенча гамәл кылган өчен алынган түләү турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

ирекле формированиеләрдә булган хәрби хезмәткәрләрнең, гражданнарның, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләренең керемнәре турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, федераль иминлек хезмәте органнары, Россия Федерациясе дәүләт саклау органнары, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле федераль дәүләт хезмәте узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең, шулай ук Россия Федерациясе Президентының махсус программалар Баш идарәсе хәрби хезмәткәрләренең һәм граждан персоналының керемнәре турында белешмәләр (хәрби хезмәткәрләрдән, ирекле формированиеләрдә булган гражданнардан, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләреннән тыш);

хәрби хезмәт, Россия Федерациясе җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль иминлек хезмәте органнарында, Россия Федерациясе дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендә хезмәт уза торган (узган) затлар тарафыннан алына торган пенсия күләме турында белешмәләр;

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр турында белешмәләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында, шулай ук оешма милке белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә) (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

керемнәр турында кертемнәр (банклардагы счетлардагы калган акчалар) буенча процентлар рәвешендә белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

авторлык заказы шартнамәләре, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы шартнамәләр буенча керемнәр турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

мөлкәтне сатудан, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән салым салына торган керемнәр турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

алына торган алимент суммасын гаризада чагылдыру юлы белән алына торган алимент турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының тулысынча дәүләт тәэминатында булуы турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзаларының чакырылу буенча хәрби хезмәт үтүе турында, шулай ук хәрби һөнәри оешмада һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмасында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән затның хәрби хезмәткәр статусы турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәвалауда булуы турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасын куллану турында белешмәләр;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы затларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендияләр, Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалата түләүләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация күләме хакында белешмәләр;

отставкага киткән судьяларга гомер буе ай саен түләнә тәэминат күләме турында белешмәләр;

дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган, алынган компенсация суммасы турында белешмәләр;

Россия Федерациясеннән читтә чыганаклардан алынган керем суммалары турында белешмәләр;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендәге хезмәттән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнардагы хезмәттән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында белешмәләр;

алынган грантлар, субсидияләр һәм эшкуарлыкка ярдәм итү кысаларында бирелә торган максатчан чыгымнарга ия булган башка керемнәр турында белешмәләр;

лотереяны оештыручылар, тотализаторлар тарафыннан һәм хәтәрлеккә нигезләнгән башка уеннардан түләнә торган, отыш нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүчедә булган очракта);

баланы дәвалауга федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм;

хәбәрсез югалган дип танылган яисә вафат дип игълан ителгән затлар турында

белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының эзләтелүдә булуы турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ турында белешмәләр.

Мөрәҗәгать итүче аның белән бергә даими яшәү урыны буенча яшәгән затларны аның гаилә әгъзалары итеп тану турында суд карары актын тапшырырга хокуклы, – мөрәҗәгать итүче белән даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәгән затлар арасында бер гаиләнеке булу мәсьәләсендә аңлашылмаучанлыклар булган очракта.

Гражданнарның гаилә әгъзалары, югарыда күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә, әлеге гражданнарның китү сәбәбен, шулай ук әлеге гражданнар киткәнче тиешле торак урында даими яшәү фактын раслаучы документларны тапшыралар.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмалардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә дә алына.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать иткәндә, үзләренең шәхесен таныклый торган һәм мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – БИАБ) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Физик зат тарафыннан бирелгән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итү хокукын раслаучы ышанычнамә нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән раслана.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкысының электрон формасы, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба - Министрлык) рәсми сайтында (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) (http://mtsz.tatar.ru) урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

шәхсән яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә гаризага тикшерү ачкычы сертификаты электрон гаризада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада төзелгән һәм кулланыла торган көчәйтелгән квалификацияле электрон имза яисә көчәйтелгән квалификациясез электрон имза белән имзалыйлар. (абзац 2024 елның 25 декабреннән үз көченә керә).

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар (белешмәләр):

мөрәҗәгать итүчеләрдә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткүгә түләү буенча законлы көченә кергән суд акты белән расланган, соңгы 3 елдан артмаган чорда барлыкка килгән, түләнмәгән бурычның булуы (булмавы) турында – Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасыннан;

торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен субсидия алучыга исәпләнгән суммалар турында һәм Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасыннан торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә субсидия алучы тарафыннан түләнгән суммалар хакында белешмәләр;

Росреестрдан мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән торак урынына ия булуының һәм аннан файдалануының хокукый нигезләре турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән үлемне дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәве турында;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан гаилә әгъзасына опека яисә попечитель билгеләү турында опека һәм попечительлек органы карарындагы белешмәләр;

хезмәт яисә башка бурычларны, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, граждан-

хокукый шартнамә кысаларында, шул исәптән түләүле шартларда опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) (шул исәптән салым тотып калынган) буенча гамәл кылган өчен алынган түләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләренең Россия Федераль салым хезмәтеннән хәрби хезмәткәрләрнең, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарның керемнәре турында (Россия Оборона министрлыгына, Росгвардиягә, Россия Федераль салым хезмәтенә, Россия Федераль салым хезмәтенә сорау буенча);

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан мәҗбүри пенсия иминияте турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда вафат булган иминләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында, шулай ук оешма милке белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә;

Россия Федераль салым хезмәтеннән кертемнәр (банклардагы счетларда калган акчалар) буенча процентлар рәвешендәге керемнәр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр турында,

Россия Федераль салым хезмәтеннән авторлык заказы шартнамәләре, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы шартнамәләр буенча керемнәр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән мөлкәтне сатудан, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән салым салына торган керемнәр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән Россия Федерациясе гражданының 2026 елның 1 гыйнварына кадәр Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм булу урыны буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан теркәлү турында -;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан 2026 елның 1 гыйнварына кадәр Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы Россия Федерациясе гражданының элек бирелгән паспортлары турында; Россия Федераль салым хезмәтеннән;

Федераль суд приставлары хезмәтеннән алына торган алиментлар турында (акчалар суд приставлары бүлегенең вакытлыча карамагына керә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан түләтүчегә күчерелгән очракта);

Җәзаларны үтәү федераль хезмәтеннән мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларын иректән мәхрүм итү урыннарында булуы турында;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан инвалидлык һәм аның төркеме (булган очракта) булуы турында;

мөрәҗәгать итүчегә һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларына карата Җәзаларны үтәү федераль хезмәтеннән сак астына алу рәвешендә чик кую чараларын куллану турында;

табигый бәла-казага яисә башка гадәттән тыш хәлләргә бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән, шулай ук террорчылык актына бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектының тиешле субъектының башкарма органы карары буенча мондый түләүләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма органыннан түләнә торган бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм суммалары турында;

Федераль салым хезмәтеннән лотереяләр, тотализаторлар һәм башка куркынычка нигезләнгән уеннарны оештыручылар тарафыннан түләнә торган отышлар нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

2.8 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның (белешмәләрнең) тулы булмаган комплектын тапшыру (ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга мөмкин булган белешмәләрдән тыш), шулай ук гаризада һәм (яисә) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүмат булу фактын билгеләү;» (абзац 2024 елның 25 декабреннән үз көченә керә)

сигезенче кызыл юлны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән барлык документларның яисә документлар өлешенең (ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга мөмкин булган белешмәләрдән тыш), шулай ук эшләп бетерелгән гаризаның һәм (яисә) эшләп бетерелгән документларның (белешмәләрнең) барлык документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр ителгән көннән алып 10 эш көненнән артык вакыт эчендә тапшырылмавы;» (абзац 2024 елның 25 декабреннән үз көченә керә)

3 бүлектә:

3.3.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш

тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Үзәк бүлечәсе белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Үзәк бүлекчәсе белгече:

Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан электрон гаризалар булу-булмавын көненә ике тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, язу тапшыра.

Документларны кабул итү һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече, гаризада ул күрсәткән ысул белән, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, гаризаны теркәү һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә (абзац 2024 елның 25 декабреннән үз көченә керә).

Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның (белешмәләрнең) тулы комплекты тапшырылмаган очракта, шулай ук субсидия бирү турындагы гаризада һәм (яисә) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүмат булу факты ачыкланган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече, тапшырылырга тиешле җитмәгән документлар (белешмәләр) исемлеген һәм (яисә) төзәтелергә тиешле мәгълүматны күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны карауны 10 эш көне срогына туктатып тору турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә (абзац 2024 елның 25 декабреннән үз көченә керә).

Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша биргән очракта, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар 3 нче кушымтадагы форма буенча мөрәҗәгать итүченең Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

3.3.1 һәм 3.3.2 пунктларында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

шәхсән кабул иткән очракта – гариза һәм документлар алынган көнне, әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрне исәпкә алып;

гариза һәм документлар Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша килгәндә яки почта, электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе көнне.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр порталы аша килгәндә яки почта аша, электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән язу, документларны кабул итүдән баш тарту турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар, гаризаны карауны туктатып тору турында хәбәр.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече мәгълүматлар ала:

мөрәҗәгать итүчеләрдә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткүгә түләү буенча законлы көченә кергән суд акты белән расланган, соңгы 3 елдан артмаган чорда барлыкка килгән, түләнмәгән бурычның булуы (булмавы) турында – Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасыннан;

торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен субсидия алучыга исәпләнгән суммалар турында һәм Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасыннан торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә субсидия алучы тарафыннан түләнгән суммалар хакында белешмәләр;

Росреестрдан мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән торак урынына ия булуының һәм аннан файдалануының хокукый нигезләре турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән үлемне дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәве турында;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан гаилә әгъзасына опека яисә попечитель билгеләү турында опека һәм попечительлек органы карарындагы белешмәләр;

хезмәт яисә башка бурычларны, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, граждан-хокукый шартнамә кысаларында, шул исәптән түләүле шартларда опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) (шул исәптән салым тотып калынган) буенча гамәл кылган өчен алынган түләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләренең Россия Федераль салым хезмәтеннән хәрби хезмәткәрләрнең, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарның керемнәре турында (Россия Оборона министрлыгына, Росгвардиягә, Россия Федераль салым хезмәтенә, Россия Федераль салым хезмәтенә сорау буенча);

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан мәҗбүри пенсия иминияте турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда вафат булган иминләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында, шулай ук оешма милке белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә;

Россия Федераль салым хезмәтеннән кертемнәр (банклардагы счетларда калган акчалар) буенча процентлар рәвешендәге керемнәр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр турында,

Россия Федераль салым хезмәтеннән авторлык заказы шартнамәләре, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы шартнамәләр буенча керемнәр турында;

Россия Федераль салым хезмәтеннән мөлкәтне сатудан, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән салым салына торган керемнәр турында;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан Россия Федерациясе гражданының 2026 елның 1 гыйнварына кадәр Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм булу урыны буенча теркәлү турында; -Россия Федераль салым хезмәтеннән – 2026 елның 1 гыйнварыннан соң;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан 2026 елның 1 гыйнварына кадәр Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы Россия Федерациясе гражданының элек бирелгән паспортлары турында; Россия Федераль салым хезмәтеннән – 2026 елның 1 гыйнварыннан соң;

Федераль суд приставлары хезмәтеннән алына торган алиментлар турында (акчалар суд приставлары бүлегенең вакытлыча карамагына керә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан түләтүчегә күчерелгән очракта);

Җәзаларны үтәү федераль хезмәтеннән мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларын иректән мәхрүм итү урыннарында булуы турында;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан инвалидлык һәм аның төркеме (булган очракта) булуы турында;

мөрәҗәгать итүчегә һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларына карата Җәзаларны үтәү федераль хезмәтеннән сак астына алу рәвешендә чик кую чараларын куллану турында;

табигый бәла-казага яисә башка гадәттән тыш хәлләргә бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән, шулай ук террорчылык актына бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектының тиешле субъектының башкарма органы карары буенча мондый түләүләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма органыннан түләнә торган бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм суммалары турында;

Федераль салым хезмәтеннән – лотереяләр, тотализаторлар һәм башка

куркынычка нигезләнгән уеннарны оештыручылар тарафыннан түләнә торган отышлар нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.».

3.5.3 пунктның өченче абзацында «календарь» сүзен «эш» сүзенә алмаштырырга.